КУРКЫТЫРГА ЯРАМЫЙ
Хуҗиннар гаиләсе каз асрауның бөтен серен белә

> 2

БЕЗДӘ – ЮБИЛЕЙ!
«Мин Светаның «ВТ»да кайчаннан эшләгәнен дә белмим. Әйтерсең без гомер буе бергә...»

> 3

ГАЛӘМ ХӘЛЛӘРЕ
«Мир» станциясендә космонавтлар ничек көн күргән?

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – монда

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 108 (29075) | Шимбә | 29 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

КАЛАГА ДА, САЛАГА ДА – БЕР

1 СЕНТЯБРЬДӘН МӘКТӘП ҺӘМ БАКЧАЛАРНЫ НИНДИ ЯҢАЛЫКЛАР КӨТӘ?

Яңа уку елыннан укучыларны, студентларны гына түгел, сабыйларны да яңача тәрбияли һәм укыта башлаячаклар. Бакчаларда белем бирүнең яңа федераль программасы, мәктәпләр өчен исә «алтын стандарт»лар әзерләнгән. Моның белән нәрсә үзгәрәчәк?

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Алтын стандарт» дигәнең бер төрле дәреслекләр, программалар буенча укытуны күздә тота. Билгеле бер дәрәҗәдән түбәнгә төшәргә, ягъни калышырга ярамый. Әлегә ул рус теле, әдәбият, тарих, җәмгыять белеме, география, тормыш иминлеге нигезләре (ОБЖ) кебек фәннәргә кагыла. Авылда да, шәһәрдә дә, дәүләтнеке булган яки хосусый мәктәптә дә – барысына да бер таләп. Яңа уку елына әзерләнүгә багышланган очрашуда Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү идарәсе башлыгы Татьяна Алексеева да бердәм программага тукталган иде. «Бала бер мәктәптән икенчесенә күчкәндә, кыенлыклар тумаячак», – диде ул.

Әгерҗе районының мәгариф бүлеге башлыгы Вәсилә Сафиуллина да әлеге яңалыкны хуплый.

– Без – совет заманында үскән балалар. Барыбыз да бердәм дәреслекләрдән укыдык. Һәм моны яхшырак иде дип уйлыйм. Дөрес, укытучылар төрле әсбапларны куллана ала, ә балаларга бирәү булачак. Чөнки стандарт та бердәм бит, – ди Вәсилә Сафиуллина.

Биектау районындагы Дөбьяз мәктәбенең рус теле укытучысы Миләүшә Хәйруллина да бердәм дәреслекләр кертүне уңай бәяли.

– Уку елы уртасында кайсыдыр шәһәр яки авылдан күченеп килгән бала укуын җайлы гына дәвам итә алачак. Менә шуны һаман оештырып бетерә алмыйлар. Узган елдан ук башламакчылар иде, тик барып чыкмады. Дәреслекләр килеп җитмәде. Китаплар соңламасын иде, – ди ул.

– Тагын нинди яңалыклар көтәсез? – дип тә сораштык аннан. Миләүшә Хәйруллина, әдәбият дәресләренең саны артсын, әти-әниләр балаларын бераз телефоннан тыйсын иде, дигән теләктә. Замана баласы әсәрне укымас өчен, теләсә нинди хәйлә таба. Әдәбият дәресләрен күбрәк укытуның зыяны юк, ди ул.

КФУның Психология һәм мәгариф институты директорының укыту эшләре буенча урынбасары, белем һәм тәрбия бирү методологиясе кафедрасы мөдире Алмаз Галимов яңа дәрес һәм дәреслекләр кертүне формаль үзгәрешләр дип саный. Аның фикеренчә, иң мөһиме – тәрбия алымнарына карата караш үзгәрү.

– Хәзер илебезнең утыз ел элек булган алымнарга борылуы сизелә. Шәхси ирек, сүз иреге, сайлау иреге... Моңа кадәр син үзең уңышка ирешергә тиеш, шул вакытта гына җәмгыятькә файда китерә аласың кебек фикерләр йөрде. Хәзер шул әйберләрдән борылырга җыеналар. Нәрсәдер үзгәртергә тырышалар, әмма кайсы якка борыласын әлегә белмиләр. Минем үземдә бераз борчылу бар. Кызып китеп ясалган кискен үзгәрешләр булмасын иде ул. Болай да сынып-сынып торабыз. Туксанынчы елларда бер тапкыр сындык, хәзер тагын бер кат сыну кирәкми. Борылыш ул әкренләп, уйланып эшләнелгән булырга тиеш. Шуны исәпкә алсыннар иде, – ди Алмаз Галимов.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАГЫН НИЛӘР ҮЗГӘРӘ?

➤Югары сыйныфларда хокук, икътисад фәннәрен җәмгыять белеме дәресендә тирәнтен өйрәтәчәкләр. Астрономия кабат физика фәненә әйләнеп кайта. Табигый фәннәр белемен, экологияне биология, химия, физика дәресләре кысасында укытмакчылар.

➤9 нчы сыйныф укучылары өчен яңа тарих дәресләре әзерләнгән. Анда Бөек Ватан сугышы, махсус хәрби операция һәм башка темалар урын алачак.

➤Тарих, җәмгыять белеме, әдәбият дәресләрендә коррупциягә каршы көрәш, ришвәт алуның куркыныч яклары турында сөйләмәкчеләр.

➤Тормыш иминлеге нигезләре (ОБЖ) фәнен Иминлек нигезләре һәм Ватанны саклау дип үзгәртәчәкләр. 10–11 сыйныфлар өчен яңартылган курста башлангыч хәрби әзерлеккә дә урын биреләчәк. Анда корал белән ничек эш итәргә кирәклеген, сафта марш атларга, противогаз кияргә, беренче ярдәм күрсәтергә өйрәтәчәкләр.

➤Киләсе елдан бөтенроссия тикшерену эшләрен (ВПР) башкаруга билгеләнгән вакытның күләме бер сәгатькә кимеячәк. Аны компьютерда тапшыруга игътибар артачак. Хәзерге вакытта ВПР нәтиҗәсе аттестат алуга, бер сыйныфтан икенчесенә күчүгә бернинди йогынты да ясамый. Менә шул ягын да уйламакчылар.

➤Мәктәпкә хезмәт тәрбиясе кайта. Әти-әниләр, балага такта сөрттерергә, идән юдыртырга ярамый, дип каршы килә алмаячак. Чөнки аларның рөхсәтен хәзер беркем дә сорамаячак. Укучылар мәктәп тирәсендә чәчәкләр, агачлар утыртуда, мәктәп китапханәсе, музейдагы һәм башка эшләрдә булышачак.

➤Көллиятләрдә «Гаилә белеме» темасына багышланган тәрбия сәгатьләре кертелә. Әлеге сәгатьләрне укытуга яшьләрнең гаилә корырга ашыкмавы да этәргеч булган. Гаилә кыйммәтләренә, аны саклауга да әһәмият бирәчәкләр.

Яңа комиссия

Татарстанда яңа комиссия төзелә. Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы әлеге комиссия даруларны, медицина кирәк-ярагын, махсус ризыкларны бер компаниядән генә алуны тәэмин итәчәк. Ул дезинфекция чаралары, ярдәмче материаллар сатып алу, медицина техникасын ремонтлау өчен дә җаваплы булачак.

Комиссия эшне оештыручыга таләпләр дә куячак. Алар арасында фармацевтика эшчәнлегенә лицензия алу, 40 миллион каптан ким булмаган күләмдә дарулар, медицина кирәк-ярагын саклау мөмкинлегенә ия булу да бар.

Яңа комиссиягә сәламәтлек саклау министры урынбасары Айрат Гарипов җитәкчелек итәчәк. Аның составына министрлык хезмәткәрләре керә.

Ура, «ФИЗРА»!

Быел республикада 16 яңа спорт корылмасы төзелә. Тагын 15 объектны капиталь төзекләндерү күздә тотыла. Спорт министрлыгының матбугат хезмәте хәбәренә караганда, Чаллы һәм Әлмәттә «Бизнес-спринт» федераль проекты буенча «ФИЗРА» спорт үзәге» физкультура-савыктыру комплекслары төзелеп килә. Ул гөмбәз астындагы ике футбол кырыннан (40х25 һәм 31х17м үлчәмендәге) һәм административ бинадан гыйбарәт булачак.

Шушы ук проект буенча Яшел Үзән районының Васильево бистәсендә модульле спорт залын, Әлмәтнең физкультура көллиятендә һәм Казанның 16 нчы татар-инглиз гимназиясендә «акыллы» спорт мәйданчыкларын булдыру күздә тотыла.

Өсте ябулы футбол кырларын төзү дә дәвам итә. Быел алар Азнакай, Актаныш, Апас һәм Питрәч районнарында пәйда булачак. 3 ел эчендә 20х40м үлчәмендәге 12 манеж файдалануга тапшырылган инде. Быел Татарстанда дүрт универсаль мәйданчык (2се – Казанда, Чаллы һәм Саба районында – 1әр) төзелгән.

Алексеевск районында Бадминтон үзәген төзү эшләре алып барыла. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның аерым боерыгы нигезендә Зәйдә өсте ябулы йөзү бассейны һәм Яшел Үзәндәге «Маяк» комплексында тернәкләндерү блогы корыла.

Вак-төяктән җыела

10 мең сумга кадәр ришвәт алган өчен 3–4 елга иректән мәхрүм итәргә, шулай ук мөлкәтне конфискацияләргә мөмкиннәр. Дәүләт Думасының Иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш комитеты рәисе Василий Пискарев Думага шундый закон проектының кертелүе турында белдергән. «Вак-төяк ришвәтчелек өчен җаваплылыкны көчәйтү турында закон проектын керттек. Биредә сүз 10 мең сумнан артмаган ришвәт турында бара. Бу бик мөһим, чөнки астагы коррупция нәкъ менә шундый вак-төяктән җыела да инде. Ә ул – зур күләмдәге ришвәт кебек үк куркыныч», – дигән сәясәтче.

Пискарев мондый җинаять кылучыларны мөлкәтеннән дә коры калдырачакларын искәрткән. Гамәлдәге законда бу күздә тотылмаган. Хәзер исә зыянны каплау мөмкинлеге булачак. «Шуны истә тотарга кирәк: теләсә нинди күләмдәге ришвәт – законны бозу ул», – дигән парламентчы. Комитет рәисе закон проектының көзге сессиядә каралачагын әйткән.

Җылыны чилләдә әзерлиләр

Татарстанда җылылык бирү чорына 2309 котельный тулы әзерлеккә куелган инде. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Мәҗит Салихов сүзләренә караганда, бу – барлык котельныйларның 74 проценты.

Министрлыкның матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, барлыгы 2417 мәгариф (74%), 1546 сәламәтлек саклау (77%), 1526 мәдәният (75%), 112 социаль яклау объекты (68%) кышка әзер.

Һава торышы

Яртысына риза буласы

Урак өчен уңай булачак. Быелгы коры җәйнең соңгы аен синоптиклар әнә шулайрак фаразлый. Августтан тагын ни көтәргә? Без шуны белештек.

«Фобос» һава торышы үзәге белгече Евгений Тишковец, Россиядә җәйнең соңгы ае рәхәт көннәргә бай булачак, дип өметләндерә. Рәхәт дигәне – артык эссе дә, суык та булмаган һава торышы инде ул. Августта илнең күпчелек төбәкләрендә һава температурасы күп дигәндә +30 градуска күтәреләчәк, дип фаразлый синоптик. Шул ук вакытта бу айда явым-төшемнәр дә климатик нормадан 10–30 процентка артып китәргә мөмкин икән.

Татарстан һәм Идел буендагы башка төбәкләрдә исә август бик эссе булырга охшамаган, ди белгечләр. Россия Гидрометеоүзәге лабораториясе мөдире Людмила Паршина хәбәр итүенчә, җәйнең соңгы аенда һава температурасы климат нормасыннан бераз түбәнрәк булачак.

«Татар-информ»

АВГУСТ АЕНЫҢ ИҢ МӨҺИМ БАКЧА ЭШЛӘРЕ

✓Бакча җиләген җыеп алуга, туфракка ашлама кертәләр һәм аны көпшәкләндерәләр. Август ахыры яңа үрентеләрне аерып утырту өчен кулай вакыт.
✓Укроп, редис һәм салат чәчәргә була.
✓Бу чорда кыярларны тукландырырга кирәк.
✓Август – октябрьдә – агачлар, сентябрь ахырында куаклар утырту өчен чокырлар казып калдырырга киңәш ителә.

Көндез терекөмеш баганасы +18...+23 градустан югары күтәрелмәс, дип фаразлана.

Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче «халык синоптигы» Рәис Шәкүров, август ае урак өчен бик яхшы киләчәк, дип ышандыра.

– Яңгырлар күренми, коры булырга охшаган. Ашлыкны җыеп алгач, киптерәсе дә булмаячак. Әле менә басуларны урап кайтып килүем: ашлык бик яхшы кипкән, өлгергән. Узган елгы уңышның яртысын җыеп алырлар кебек – шуннан артыгы булмас, – ди ул.

Быелгы җәй иртә килде, көзе дә шулай ашыгырмы икән? Рәис абыйдан шуны сорадык.

– Юк, үз вакытында киләчәк ул. 29 августтан 10 сентябрьгә кадәр тоташ яңгырлар күренә. Бәрәңге алганда яхшы булмас анысы, – диде «халык синоптигы». – Ләкин мин гел әйтәм: бәрәңгене сентябрь ахырында гына алырга кирәк. Соңрак алган саен, бәрәңге тәмлерәк кенә була. Суык туфракта яхшырак үсә бит ул. Узган ел үзебез 28–29 сентябрьдә алган идек, әле дә иске бәрәңге сатам. «Тәмле», – дип әйтеп алалар.

Рәис Шәкүров сүзләренә караганда, быел бәрәңгене иртә утырткан һәм аңа су сипкән кешеләр отачак. Әмма алар да әле узган елгы уңышның яртысын гына җыеп алырлар, дип фаразлый ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сүзгә-сүз

Борис ГЕРАСИН, юрист:

Мәгълүмати сугышта һөҗүм алымы еш кулланыла. Аны, шартлыча, вирус дип атыйк. Аның белән көрәшүнең төрле ысуллары бар. Терапия белән генә шөгыльләнеп, яңалыклар укырга, алар турында кем белән булса да сөйләшергә, иза чигәргә була. Икенче юлы – «вакцина» ясау. Ягъни тәнкыйди фикерләүне үстерү, мәгълүматны тикшерергә өйрәнү.

(«RT. Док: Время героев» фестивалендәге фикер алышуда сөйләгәннәрдән)

РОССИЯДӘ – БЕРЕНЧЕ ХЕЗМӘТ ХАКЫ

«Росгосстрах» һәм hh.ru эш эзләү хезмәте белгечләре илдә яшәүчеләрдән тәүге хезмәт хаклары һәм аны нәрсәгә тотулары турында сорашкан.

25%	>> кием-салым сатып алган
21%	>> әти-әнисенә биргән
21%	>> бернәрсәгә дә тотмаган, саклаган
20%	>> күңел ачу чараларына тоткан
14%	>> гаджет сатып алган
10%	>> уку өчен түләгән

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Белем, бәхет һәм девальвация

Халык гыйлемле булса икән ул. Бар булган гавам югары белемле булып бетә алмый, әлбәттә. Әле, бер танышым әйтмешли, югары белем дигәндә дә аның югарылыгы шик уята. Гыйлемлеләр, гыйлемнең кадерен белгән кешеләр өлеше илдә күбрәк булса иде, диюем.

Гыйлемлелек ул – зурдан алганда, җәмгыятебезне күздә тотып әйткәндә, проблемалардан гына түгел, бәлаләрдән дә котылу чарасы бит. Белеме булганны адаштыру, саташтыру кыен. Белемлеләр кешелекле, гаделрәк. Белемле бәндә мәдәниятлерәк тә әле. Мәдәниятле кеше, уртакул адәми зат белән чагыштырганда, әйләнә-тирәне гармонияле, шәфкатьлерәк, яктырак итә. Гыйлемле ата-ана да башка. Шул ук укытучы баласы, йөз процент очракта димим, барыбер тәрбиялерәк, максатчанрак, тәртиплерәк. Һәрхәлдә, элек шулай булды.

Бу юллар авторы без яшәгән бүгенге җәмгыятьтә гыйлемлелек девальвациясе күрә. Белемнең культ дәрәҗәсендә йөрмәгәнлеген әйткән дә юк. Культ дигәндә, аңа бүген диплом дәгъва итә. Вуз дипломы булган кешеләр күбәя, тик гомуми белемлелек артмый. Вуз тәмамлаган – дипломлы, тик аларның хәтсез өлеше – белемсез яки ярты-йорты белемле. Гомуми эрудиция, интеллектны әйтмим, дипломда күрсәтелгән белгечлек буенча да яшьләрнең хәтсез өлешенең белеме техникум дәрәҗәсенә тарта микән? Икенче сорау: ни өчен шулай? Төпкәрәк төшеп уйлаганда, бу хәлнең шактый гади механизмы шәйләнә.

Теләсә кайсы әти-әни үз баласының уңышлы булуын тели. Уңышлылыкны ул турыдан-туры югары белем белән, бүгенге тилемсә жаргон белән әйткәндә, «вышка»га бәйли. «Күршенең баласы кердe, укып йөри ич, фәлән-фәлән танышларныкы да вуз бетерде, әллә минем газизем алардан кимме? Һич юк! Исең киткән икән, мәктәптә «өчле»гә барды. Институтта аның яңа сулышы ачылачак. Акча да, бернәрсә дә жәл түгел, укысын гына, дипломлы булсын». Нәкъ менә шундый фәлсәфә, шундый уй сөреше урта мәктәп тәмамлаганнарның 80–90 процентын югары уку йортларына илтә дә. Шул ук совет чорында андый «киң укымышлылык» юк иде. Вузларга кичәге укучыларның 20 процентлан да артыгы кермәде. Тик гомуми гыйлемлелек күпкә югары булды.

Вуз дипломлы сатучылар, слесарьлар, йөк ташучылар, тагын әллә кемнәр… Кичәге студент үз белгечлеге буенча йә урнаша алмый, йә теләми. Юрист, менеджерларның, икътисадчыларның, мәсәлән, бүген исәбе-саны юк. Тик аларны һаман да үрчетәләр. Аларны хәтта техник вузлар да чыгарды һәм чыгара. Кирәләр, диплом алып чыга торалар. Чөнки ул юнәлешләр буенча түләү кимеде. Ә диплом барыбер булачак. Белгечлек буенча эшләмәү тәмам модага кергәндә шәп ич.

Белем сайлыгы да дипломдагы белгечлек буенча эшләмәүгә китерә. Башка өлкәдә эшлисең икән, синең наданлыгың кычкырып тормый. «Башка һөнәргә укыган идем шул», – диясең дә куясың, вәссәлам. Язып торуларынча, илдә 10–15 миллион чамасы югары белемле кеше үз белгечлеге буенча эшләми. Сорау туа: алайса, алар ник укыган, ник ул белгечлекне алган? Кеше бит нәкъ менә дипломда күрсәтелгән һөнәр буенча тир түгәргә, илгә, халык хуҗалыгына файда китереп торырга, аны алга илтергә тиеш. Бу – алдынгы икътисадка ирешүдә төп шартларның берсе: барын да кадрлар хәл итә.

Кемнәрнеңдер үзләренең иң гүзәл елларын, киләчәктә бөтенләй кирәкмәячәк фәннәрне өйрәнеп вакыт үткәрүен аңлау ифрат та авыр. Ә түләнгән акча? Вакытны бушка уздырганчы, киләчәктә кирәкмәячәк белем өчен олы сумма чыгарып салганчы, шул ук көллият дипломы белән акча эшләргә тотынырга, тәҗрибә, стаж туплый башларга, югары квалификацияле эшче булып китәргә мөмкин бит. Бүген нәкъ шундыйлар җитешми. Кайбер рәсми саннарга ышанганда, биш ел эчендә миллионга якын сум түләп вуз тәмамлаган маркетологларның, мәсәлән, уртача хезмәт хакы 44 мең сум булса, югары белемгә ия булмаган шундый ук һөнәр иясенең 41,5 мең сум тәшкил итә. Күрәбез: аерма шактый кечкенә. Фәлән ел буе аудиторияләрдә, кем әйтмешли, ыштан туздыруның әҗере ташка үлчим.

Россиядә бүген югары белемле халыкның өлеше – 31 процент. Ягъни якынча һәр өч кешенең берсе вуз дипломлы. Бу күрсәткеч буенча Европада бездән Бөекбритания (36 процент) белән Швеция (34 процент) генә алда бара. Евросоюзның беренче иле, дөньяның дүртенче икътисады саналган Германиядә ул процент – 29, Франциядә 23кә тигез. Ягъни сан буенча без аларны уздык, тик менә сыйфат ягы…

Гаҗәеп ил шул без. Гаҗәп менталитетлы, холык-фигыльле. Россиянең үзенчәлеге шунда: кайдан, нинди дә булса үрнәк, алдынгы тәҗрибә алабыз икән, без аны биредә еш кына үзебезгә, үз менталитетыбызга яраклаштырып үзгәртәбез, боргалыйбыз, хәтта ки бозабыз. Бозмаска, боргаламаска иде. Биредә хәзер демократияне, аңа бәйле бәйле багланышларның да тетмәсен тетү модада. Без аны да бирегә алып, кулланып карадык. Бездә ул барып чыкмады. Демократик кыйммәтләр дә биредә девальвациягә дучар булды, аерым бер категория халык өчен сүгенү сүзенә әйләнде. Тик шунысы хак: андый мөнәсәбәтләргә, указ чыгарып, берничә айда, елда гына ирешү мөмкин түгел. Демократиягә озак еллар буе, бар булган сабырлыкны, зиһенне, теләкне җыеп өйрәнәсе. Биредә барып чыкмаган демократия андый идарә формасының начарлыгын аңлата микән? Юктыр.

Тарихыбыз шундый, без биредә ирекнең нәрсә икәнен дә белмибез. «Вольница» дигәне – «ни телисең – шуны эшлә» ише тәртипсезлек, башбаштаклыклар исә булгалаган. Андыйның демократия белән бер уртаклыгы да юк. Чын ирек-хөрлек ул – беркемгә дә зыян салмый торган, нәтиҗә бирә торган тәртипле «вольница». Ә белем системасына кайтканда, бездә хәзер «вольница»ның начары, җисеме исеменә туры килгәне. Белем дигәндә, аның ахыр килеп, алгарышка, сыйфатлы яшәешкә барып тоташканын белгәндә, нәкъ менә тәртипле ирек, ирекле тәртип мөһим. Ә бездә, ни кызганыч, озын чорлар буе законга да хөрмәт булмаган. Әле дә бик күзәтелми. Кешегә, шәхескә дә. Без анысына да өйрәнергә тиеш. Халык та, хакимият тә бөеклек дип түгел, бәхетле, гадел җәмгыять, тәртипле хөрлек дип тырышса, җан атса гына нәтиҗә булачак. Шунысын да билгелик: бөеклек белән бәхет янәшә яши торган сыйфатлар түгел. Аларның йә берсе була, йә икенчесе.

Сүземне: «Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә. Һәммәсе дә зурлап баш ия гыйлемлегә», – дип тәмамлыйсым килә. Белемле булыйк!

ӘШЕНӘ КҮРӘ – АШЫ

Һөнәр иясе

Завод эшчесе дигәч тә, терсәктән майга чумган урта яшьтәге абзый күз алдына килдеме? Ай-һай, ялгышасыз. Бүгенге предприятиеләр замана белән бергә атлый. Шуңа күрә бирегә яшьләр дә теләп килә. Башкаладагы «Точмаш» заводында эшләүче егет-кызлар: «Биредән китәргә дә теләмибез», – ди әнә.

Илсур Баһаутдиновка егерме яшь. Ул былтыр Казан авиация көллиятен тәмамлап, заводка эшкә килгән.

– Укыган вакытта «Точмаш»та практика уздым. Заводтагы эш шартлары шул вакытта ук ошады, – ди егет. – Мин – оператор. Үз белгечлегем буенча хезмәт итәм. Эшем чип-чиста. Станокларны кирәгенчә көйлим дә алар деталь җитештергәнне күзәтеп торам. Бүген яшьләр заводка эшкә килми, дигән фикер белән, гомумән дә, килешмим мин. Хәзерге зур оешма-предприятиеләр заманча техника белән җиһазландырылган, биредә эш өчен бөтен шартлар да бар. Көллиятне тәмамлауга, бирегә килдем. Монда иптәшләрем дә шактый. Чөнки яшьләрне кызыктыра беләләр. Миңа, мәсәлән, укуымны дәвам иттереп, вузга керергә тәкъдим иттеләр. Әлегә уйлыйм. Мин дә, цехтагы башка яшьләр дә биредән китәргә җыенмыйбыз. Ялларда бергәләп футбол уйнарга йөрибез. Әле күптән түгел генә Зөя шәһәр-утравына экскурсиягә алып бардылар. Завод – үзенә күрә бер дөнья. Биредә карьера ясыйсым килә.

Күпме хезмәт хакы алганын гына әйтмәде Илсур. «Яшь кешенең бөтен кирәк-ярагына җитә», – дип кенә чикләнде ул. Саубуллашканда: «Мондагы кебек тәмле ризыкларны бүтән беркайда да ашаганым юк», – дип тә өстәде. Хезмәткәрләр эштән дә, аштан да канәгать, димәк.

«Казан төгәл машина төзелеше заводы» («Точмаш») федераль казна предприятиесенең тарихы 1941 елдан башлана. Бөек Ватан сугышы башлангач, завод җиһазларын һәм эшче көчләрне Ленинград шәһәреннән Казанга күчерәләр. 1941 елның 7 ноябрендә завод фронтка тәүге продукцияне төяп озата да инде. Сугыштан соң предприятиедә тыныч тормыш өчен кирәкле товарлар җитештерүне дә җайга салалар. 1981 елда завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Бүген биредә тирәнтен үзгәртеп кору һәм техник җиһазландыру эшләре тормышка ашырыла. Сәнәгатьне яңарту бәрабәренә көндәшлеккә сәләтле продукция җитештерү күләмен дә арттырмакчылар. Завод эшчәнлеге сәнәгать һәм санитария куркынычсызлыгы, әйләнә-тирә мохитне саклау кагыйдәләренә җавап бирә.

Завод эшчеләренең хезмәт хакларын «ВТ» хәбәрчесе дә белеште. «Точмаш»ның матбугат хезмәте тәкъдим иткән рәсми мәгълүматларга караганда, бүген биредә югары хезмәт хаклы биш эш урыны буш тора. 5 нче разрядлы автоматларны һәм ярымавтоматларны көйләүченең, мәсәлән, айлык хезмәт хакы 80000 сумнан башлана. Бу вазыйфага дәгъва кылучылар Mitsubishi 32-41 MRA автоматларын, агрегатлы станоклар, аз фрезерлы станоклар, буйга кыручы токарь автоматларын белергә тиеш. 5 нче разрядлы автомат линияләрне һәм агрегат станокларны көйләүчегә дә ай саен 80000 сумнан башлап хезмәт хакы вәгъдә итәләр. Соңгылары автоматлар һәм ярымавтоматларны көйләү, шулай ук бер шпиндельле һәм күп шпиндельле автоматларны көйләү күнекмәләренә ия булырга тиеш, дип аңлаттылар матбугат хезмәтендә. 2 нче разрядлы программа белән идарә ителешле станоклар операторының айлык акчасы исә 65000 сумнан башлана. Аларга шул исәптән эшкәртү процессларының тотрыклылыгын – контрольдә, җиһазларны тәртиптә тоту бурычы куела.

Эльвира ВӘЛИЕВА

«Бездә вакансияләр күп»

Светлана РУЛЬКОВА, «Точмаш» заводында кадрлар белән эшләүче белгеч:
– Заводка 18 яшьтән 60 яшькә кадәрге кешеләр эшкә урнаша ала. Эш тәҗрибәсе дә мөһим түгел. Без белгечләрне үзебез әзерлибез. Иң беренче чиратта, җыючы, оператор, контролер, станокчы һәм радиоэлектрон аппаратураны монтажлаучылар кирәк. Без төп әнә шул юнәлешләр буенча хезмәткәрләр туплыйбыз. Эшкә урнашырга дип килгән кешенең махсус белеме яки эш тәҗрибәсе булса, аның белән аерым сөйләшәчәкбез һәм, бәлки, кызыклырак тәкъдимнәр дә ясарбыз. Буш вакансияләр күп. Заводта хезмәт хакы 50 мең сумнан башлана. Айлык акча ярты ел саен индексацияләнә. Хезмәткәрләр бушлай медицина тикшерүе узу хокукына ия. Аларга тулы социаль пакет һәм эш киеме бирелә. Моннан тыш, кирәк булса, торак белән тәэмин итү һәм эшкә йөрүгә киткән чыгымнарны каплау да каралган. Зыянлы эштә эшләүчеләргә башка ташламалар да бар. Аерым алганда, пенсиягә иртәрәк чыгарга мөмкин. Тулырак мәгълүматны 8(843) 278-26-25 яки 8-987-185-40-77 телефон номерлары аша белешә аласыз.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе **Гафаров** Шамил Хәмит улы Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

***

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп итүгә әзерләнү һәм аны үткәрүдәге хезмәтләре өчен Үзәк дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие **Сәмигуллин** Камил Искәндәр улына Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Сәламәтлек

Әгәр бергә булсак...

Коммерцияле булмаган оешма белән кеше сәламәтлеге арасында нинди уртаклык бар? Баксаң, алар кеше өчен иң кадерле саналган нәрсәне саклауда уртак эш башкара икән. Чыгу юлын таба алмаган кешеләргә ярдәм итәргә тырышалар.

«Тест для Победы» проекты ВИЧ һәм башка инфекцияләргә каршы аноним рәвештә тест узарга мөмкинлек бирә. «Яңа гасыр» коммерцияле булмаган хәйрия оешмасы җитәкчесе Лилия Таишева әйтүенчә, өч ел эчендә 75 меңләп кеше тикшеренгән. Татарстанда барлыкка килгән әлеге проект Россиянең тугыз төбәген колачлый алган. Тест-мобиль белән күрше төбәкләргә дә барып кайтканнар. Сан теле белән әйтсәк, 170 меңнән артык чакрым юл дигән сүз бу. Әмма, Лилия Таишева әйтүенчә, әлеге проектның максаты кешеләрнең саулыгын тикшерү генә түгел. Мәгънәсе – тирәндәрәк.

– Тест уздыру гына түгел, максат – кешеләрнең аңын, чиргә булган мөнәсәбәтен үзгәртү дә, – ди ул. – Моның өчен мәгълүмати яктан да күп эш башкарылды. Аның кысасында 60 млн кешене җәлеп иттек. Гомумән, 2020–2023 еллар аралыгында 23 меңнән артык кеше ВИЧ-тест, 2,2 меңнән артыгы С гепатитына каршы тест узды. Проект ярдәмендә 113 мең тапкыр мәгълүмати, хокукый һәм медицина хезмәте күрсәтелде. Болар барысы да түләүсез. Саннарга сан итеп кенә карарга кирәкми. Саннарда да – кеше язмышлары. Бу – үз сорауларына җавап тапкан, тест узган, консультация алган кешеләр.

Зилә ВӘЛИЕВА, Татарстан Иҗтимагый палата рәисе:
– Коммерцияле булмаган оешмаларны үзебезнең Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә дә беләләр. Алар танылган. Безгә тәҗрибә уртаклашырга да киләләр. Коммерцияле булмаган оешмалар белән эш тәҗрибәбез зур. Коммерцияле оешмалар теге яисә бу сәбәпләр аркасында игътибарсыз калган өлкәләргә үтеп керә. Аларның социаль-икътисадый яктан да, җәмгыятькә файда китерү җәһәтеннән дә керткән өлешләре зур.

Онытылды, димә!

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина һәм Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов республикадагы санитар-эпидемиологик вазгыять турында сөйләде.

COVID-19. Кимесә дә, бетмәгән. Коронавирус турында сүзебез. Хәзер чир йоктыруның күпчелек очраклары (93 проценты) симптомсыз яисә ОРВИ рәвешендә үтә. Гадәттәгечә, COVID-19ның омикрон дигән штаммы өстенлек итә.

Дмитрий Лопушов әйтүенчә, Татарстанда коронавирус белән авыручыларга стационар ярдәм 11 медицина оешмасында күрсәтелә. Чирләүчеләр өчен 200дән артык койка-урын бар.

КЫЗАМЫК. Аның каравы кызамык чире белән авыручылар саны арта. Хәзер республикада андыйларның саны 83 кешене тәшкил итә. Шуларның 38е – балалар. Чирләүчеләр арасында 41 кеше – чит илнекеләр. Любовь Авдонина аңлатканча, алар арасында өстенлекне Таҗикстаннан килүче кешеләр алып тора (33 кеше). Шунысы да аяныч: чирләүче кешеләрнең 67 проценты кызамыкка каршы прививка ясатмаган булган.

ТЫЧКАН БИЗГӘГЕ. Республикада бу чирне йоктыручылар күп. Роспотребнадзор белгече китергән мәгълүмат буенча, 391 кеше. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, чирләүчеләр саны икеләтә арткан. Әйтүләренә караганда, чирне урманда, йорт тирәсендә йоктырып мөрәҗәгать итүчеләр саны өстенлек итә. Моның сәбәбен профилактика кагыйдәләрен санга сукмаудан да күрәләр.

– Кызганыч, йортларында эшкәртү һәм дезинфекция үткәрү хезмәтеннән баш тартучылар белән очрашырга туры килә. Ә бит бу кимерүчеләр күп булган урыннарда кирәк, – дип кисәтте Любовь Авдонина. Югыйсә мондый хезмәт бушлай күрсәтелә.

ТАЛПАН КАДАЛУ. Ел башыннан 6,8 мең кеше талпан кадалудан зыян күргән. Шуңа да карамастан, былтыргы саннан 8 процентка кимрәк күрсәткеч бу. Моңа һава торышының эссе булуы да йогынты ясаган ди. «Талпаннар эссене үз итми. Шуңа да актив түгелләр», – диде бу җәһәттән Любовь Авдонина. Талпан энцефалиты өч очракта ачыкланган.

«БАР ДА БАР, ВАКЫТ КЫНА ЮК»

«Авылга кайтасы килмичә генә кайткан идем, хәзер моннан да рәхәт җир юк төсле». Алабуга районының Морт авылында яшәүче Гөлнара Хуҗина әнә шулай ди. Ул үзе тумышы белән Кайбыч районының Борындык авылыннан. Ире Илнар – Морт егете. Өйләнешеп, Казанда берничә ел яшәгәннән соң, гаилә башлыгының күңеле туган якларга тарта башлый.

Зөлфия Хәлиуллина

Шулай итеп, беренче балалары тугач, Алабугага күченеп кайталар. Анда тагын бер балалары туа. Йорт салып бетергәч, 2012 елда Мортка кайтып төпләнәләр. Әле башкалада яшәгәндә үк кошчылык белән шөгыльләнергә ниятли алар. Программада катнашып, инкубатор да алалар. Шулай итеп, 2017 елда 250 бәбкә чыгарып, кошчылык тармагын өйрәнә башлыйлар.

– Илнар белеме буенча педагог, Казанда да эше бар иде. Ләкин күңеле авылга тартылды. Ул туган якларына кайтырга тәкъдим иткәч тә, тиз генә ризалык бирәсем килмәде, чөнки шәһәрдәге эшем бик яхшы иде. Баш хисапчы булып эшләдем. Авылга кайткач та, ияләшеп китү авыр булды. Ләкин хәзер монда яшәү ошый безгә, – ди Гөлнара ханым.

– Авылда бар нәрсә дә бар, буш вакыт кына юк. Хуҗалыкны калдырып, беркая чыгып китеп булмый, – дип сүзгә кушылды Илнар. – Без хәтта кышын да ял күрмибез. Декабрь башында казларны эшкәртеп, эшен бетерәбез дә яңа сезонга әзерләнә башлыйбыз.

Алдан ук ният-планнары булгач, бик тырышып тормыш итә башлыйлар. Тормышларын түгәрәкләп, ике бала янына тагын өчне алып кайталар. Инде буй җиткезгән егет һәм кызлары бар. Авылда алар да эшкә өйрәнеп үсә, дип сөенә Хуҗиннар.

Эшне иске фермалар сатып алып, берсенә тулысынча реконструкция ясаудан башлыйлар. Беренче елларда 250 каз бәбкәсе чыгарган булсалар, хәзер инде ел саен 1–1,5 мең каз үстерәләр. 2017 елда «Башлангыч фермер» грантын да алалар.

– Үзебезнең инкубаторыбыз булгач уңайлы. Башта бәбкә килеш, аннан соң бер айлык каз сатабыз. Эшкәрткән казларны да сату белән авырлыклар юк, чөнки безнең инде даими алучыларыбыз бар. Алып бетереп баралар. Казларны түшкәләп тә, ыслап та, каклап та сатабыз. Халык барысын да яратып ала. Туй, никах мәҗлесләренә, Яңа ел табынына күпләп алып китәләр, – ди хуҗабикә.

Илнар Хуҗин әйтүенчә, кош авыруларын белүче ветеринарлар булмавы читен. Аның каравы кешегә өмет баглап торасы юк, барысын да үзең башкарасың.

– Ветеринарларның күпчелеге мөгезле эре терлекләрне генә дәвалый. Шуңа күрә барысын да үзебезгә өйрәнергә, укырга туры килә, – ди ул.

Инде алты ел сыналып, өйрәнеп, тәҗрибә туплап, кошлар, кошчылык турында бик күп гыйлем туплаганнар.

– Кошлар чисталык ярата. Аслары юеш, пычрак булса, алар ятмый да. Кычкырып тик йөриләр. Ите тыгызланып, каралып китсен өчен суяр алдыннан казга коры бодай ашатырга кирәк. Яхшы, өлгергән каз-үрдәкнең ите тыгыз, карасу төстә булырга тиеш. Алар гадәттә төнлә ашыйлар һәм үсәләр, шуңа күрә төнгелеккә ризыктан һәм чиста судан өзмәү яхшы, – дип киңәшләре белән дә уртаклашты Илнар.

Моннан тыш, суйган вакытта казны куркытырга ярамый, чөнки калганнары шырпылана, ашаудан кала, ябыга.

– Шуңа күрә шәхси хуҗалыклар бер көндә эшкәртеп бетерергә тырыша. Без дә кошларны куркытырга тырышмыйбыз, җай белән генә берничәсен бүлеп алып калабыз да, башка юлдан алып чыгып китәбез. Калганнары тотып алганны күрми кала, – ди Гөлнара ханым.

Казларны исә өмә җыеп эшкәртәләр. Ярдәмчеләрне күрше авыллардан алып киләләр. Хуҗиннар кара казлар үрчетә. Быел токымнарын бераз үзгәртмәкче булып, Мәскәүдән Линда токымлы каз йомыркалары кайтарткannар. Ләкин алар чиста түгел, катнаш булып чыккан. Нәтиҗәдә төрле төсле казлар булып үсеп җиткәннәр. Кошчылар әйтүенчә, казларның өлгерү вакыты төрлечә. Ул беренче чиратта ашауларына бәйле. Тулысынча катнаш ризык кына ашатсаң, ике айда да өлгерә, тик андый казларның ите бик үк тәмле булмаска мөмкин икән.

– Эше мәшәкатьле, вакытны күп алса да, бер төшенгәч, яратып эшлибез, – ди Гөлнара һәм Илнар Хуҗиннар. – Авылда тырышып яшәгән кешенең тормышы да, табыны да һәрвакыт мул һәм бәрәкәтле була.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Татарстанда кош гриппына каршы профилактика максатыннан 10 июльдән 9 августка кадәр «Акчарлак» айлыгы игълан ителгән иде. Мәгълүм булганча, быел төрле төбәкләрдә кош гриппын акчарлаклар йоктырган очраклар артты. Шуңа күрә бер ай дәвамында акчарлаклар тупланган урыннар (су объектлары һәм аларга якын территорияләр, чүплекләр, калдыклар урнашкан җирләр, кош оялары) даими тикшерелә, шәхси хуҗалыклар һәм кошчылык фермалары белән аңлату эшләре алып барыла. Белгечләр шулай ук кошларның үз-үзләрен тотышында һәм сәламәтлегендә үзгәрешләр булган очракта, һәлак булган һәм авыру кыргый кошларга, бигрәк тә акчарлакларга юлыкканда кичекмәстән ветеринария белгечләренә хәбәр итәргә киңәш бирә.

СВЕТИК, ПРИВЕТИК!

Үзебезнекеләр

Редакция коридорына аяк басуга җырлый башлавым арына алмаслык бер чиргә әйләнеп бетте бугай инде. Светлананы күргәч, тавышыма аерым бер төсмер бирәм, кайчак көйне дә бераз бозам. Моны махсус эшлим, чөнки Светлананың тәнкыйте үзе бер кызык. Шулай кыланып җырлаганымны ишетүгә, мине оялта башлый: «Үз җырларыгызны ник бозасың, Риман абый, как тебе не стыдно!» – ди. Аннан соң: «Ну-ка, еще раз спой эту песню, но только пой нормально!» – дип, яннан китми торырга мөмкин.

Анна Арахамия

Светлана Афонина бездә кассир-бухгалтер булып эшли, «ВТ»да бердәнбер рус кешесе ул. Әмма без аның башка милләтнеке икәнен тоймыйбыз да. Мин дә аңа кайчак онытылып китеп татарча сорау бирәм, ә ул русча җавап бирә һәм мин кайсы телдә аңлашканыбызны да онытып җибәрәм. «ВТ» кызларыннан берсе миңа: «Света татарча да белә ул, сөйләшми генә, бер мәртәбә үпкәләткәннәр аны. Татарча аңламый дип, үзе барында кыек сүз әйткәннәр. Шуннан соң тел яшерә торган булып калган», – дигән иде. Светаның үзеннән төпченмәдем инде, неудобно булыр, дидем. Тик аның телгә бик сак каравын беләм. Ана телен санга сукмаганнарны җене сөйми аның. Татарстанда яшәп, татарча сөйләшмәгән татарларга шакката ул. «Как так можно!» – ди. Мондый хәл аның башына сыймый.

Бер елны редакциядә Яңа елны каршылап, матур гына бәйрәм оештырдык. Камал театрыннан газетабызның дусты Әсхәт Хисмәтовны да чакырган идек. Баянчы улы Булат белән килде ул, матур-матур җырлар башкарды. Аннан соң «Галиябану» спектакленнән бер күренеш уйнап күрсәтмәкче булды. «Үзем Хәлилне уйныйм, кайсыгыз Галиябану ролен башкарырга тели?» – диде. Бездә, кем әйтмешли, бер көтү кыз, әмма Галиябану булып уйнарга теләүче табылмады. Шунда Света: «Сама буду играть», – димәсенме?! Менә дигән итеп уйнады Света, бу күренеш бәйрәмебезнең иң матур бизәкләреннән берсе булды дисәм дә, ялгышмыймдыр.

Тагын бер кызыклы хәл: мин Светаның «ВТ»да кайчаннан бирле эшләгәнен белмим. Әйтерсең лә без гомер буе бергә. Мондый хис иң якын кешең турында уйлаганда гына туадыр, мөгаен. Мин Светлананың гаиләсе турында да берни белмим дияргә була. Минем өчен ул уңган-булган кыз – Светик. Исәнләшкәндә дә, Светик, приветик, дим. Аның бүген, ягъни 29 июльдә туган көне икәнен дә онытып җибәргәнмен. Ярый әле хезмәттәшләрем исемә төшерде: «Светигыңны котларга онытма», – дип тә куйдылар.

Менә шулай, Светик, туган көнең белән сине! Хезмәттәшләрең дә, әлбәттә инде, мин дә бүген 55 яшь тулуын да искә алып, сиңа ике «5»ле куябыз.

Приветик, дорогая Светик!

Риман абыең.

Ярдәмсез калмыйлар

Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә бушлай юридик ярдәм күрсәтәчәкләр. Татарстанда гамәлдәге канунга үзгәрешләр керткәннәр. Белгечләргә нинди сораулар белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин икәне дә билгеле.

Бушлай юридик ярдәм алу хокукы федераль канун нигезендә 2011 елда ук беркетелгән. Шул вакыттан бирле документка дистәләгән төзәтмә һәм өстәмә керткәннәр инде. Соңгысын бу елның июнендә кабул иттеләр. Ул махсус хәрби операциягә бәйле. Федераль үзәктән калышмыйча, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары да язгы сессиянең соңгы утырышында республика канунын үзгәртте.

– Әле күптән түгел генә, 13 һәм 24 июньдә бушлай юридик ярдәм турындагы федераль канунга үзгәрешләр керде. Без исә республика законын аңа туры китереп төзәттек. Әлеге яңалыкның асылы бушлай юридик ярдәм алучылар исемлеген киңәйтүдән гыйбарәт, – дип аңлатты Татарстан Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты җитәкчесе Шакир Яһудин.

Моңа кадәр белгечләргә бушлай мөрәҗәгать итү хокукына аз керемлеләр, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, ятим балалар һәм башка кайбер категория гражданнар ия булса, хәзер әлеге исемлекне махсус хәрби операциягә катнашы булучылар белән дә тулыландырганнар. Ил күләмендә сүз йөзәрләгән мең кеше һәм аларның гаиләләре турында бара, дип фаразлана. Алар арасында шул исәптән хәрбиләр, дәүләт сак органнары, Хәрби прокуратура, Тикшерү комитеты хезмәткәрләре дә бар. Моннан ары бушлай юридик ярдәмгә мобилизацияләнүчеләр, контракт буенча хәрби хезмәткә китүчеләр, аларның гаиләләре дә өмет итә алачак.

– Төп шарт – әлеге категория гражданнар Украина, Донецк һәм Луганск халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләрендәге махсус хәрби операциядә яки махсус хәрби операция зонасы белән чиктәш булган ил төбәкләре территориясен саклауга бәйле бурычларны үтәүдә катнашырга тиеш, – ди Шакир Ягудин.

Шул ук вакытта белгечләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин булган сораулар исемлеген дә киңәйткәннәр. Хәзер юристлар махсус хәрби операциядә катнашучыларга тиешле түләүләрне, социаль ташламаларны рәсмиләштерергә бушлай ярдәм итәчәк. Хәрбиләрнең туганнарына солдатның хәбәрсез югалуы яки үлемен раслауга бәйле мәсьәләләрдә дә булышачаклар. Тагын бер яңалык инвалид балалар һәм аларны тәрбияләүчеләргә бәйле. Дәүләт аларга да бушлай юридик ярдәм тәэмин итәчәк.

Фикер

Айнур ГАЛИМОВ,
Татарстан юстиция министры беренче урынбасары:
– Гамәлдәге канунга кертелгән үзгәрешләр нигезендә бушлай юридик ярдәм хәзерге вакытта махсус хәрби операция зонасында булучыларга гына түгел, ә аннан инде әйләнеп кайтучыларга да, шул исәптән 2014 елның маеннан башлап хәрби бурычын үтәүчеләргә дә кагылачак.

pixabay.com

ГАЛӘМНӘН – ТЫН ОКЕАНГА

Йолдызлыда күргәннәр

Юрий Гагарин исемендәге Космонавтлар әзерләү үзәгендә сәяхәтебезне дәвам итәбез. «Мир» орбиталь станциясенең тулы размерлы макеты куелган зал хәзер инде тарихи урын булып кына калган. Әмма моннан туристлар өзелми. Без дә, станциянең эченә кереп, космонавтларның көнкүреше, гомумән, космоста ничек эшләүләре белән таныштык.

Юыну

Станциянең эче әллә ни зур түгел. Башта без, бу бәләкәй генә урында вакыты-вакыты белән берничә космонавт ничек яшәгәннәр дә ничек эшләгәннәр икән дип, бик гаҗәпләндек. Бу сорауны «Мир» станциясе белән таныштырырга алынган үзәк белгече Сергей Евсеевка да бирдек. Хатын-кызларга хас булганча, юына торган урыннар эзләдек. Ахыр чиктә станциядә душ кебек җиһазның бөтенләй юк икәнлеге ачыкланды. Космонавтлар дымлы сөлгеләр белән сөртенәләр икән. Сергей Павлович сөйләгәнчә, «Мир» станциясенә кайчандыр душ куелган булган. Әмма галәмдә гравитация (ике матдәнең бер-берсенә тартылу көче) булмаганлыктан, сабын белән су тәнгә ябышкан һәм космонавтларга үзләрен дә, кабинаны да ышкырга туры килгән. Нәтиҗәдә егетләр душны саунага әйләндерергә карар кылганнар. Үз вакытында аларга хәтта мунча себеркеләре дә җибәрә алганнар. Әмма температураның әле югары, әле түбән булуы, җитәрлек дәрәҗәдә җилләтеп киптерергә мөмкинлек булмау сәбәпле, станциядә гөмбәчекләр пәйда булган. Сәламәтлеккә куркыныч тудырмасын дип, душ кабиналарыннан бөтенләй баш тартырга туры килгән.

Безне бигрәк тә хатын-кыз космонавтларның озын чәчләре кызыксындырды. Баксаң, чәч юу өчен махсус коры шампунь бар икән. Аны чәчкә һәм башка сөртәсе дә дымлы сөлге белән сөртеп кенә аласы. Космонавтларның теш пастасы да «ашый торган» булып чыкты. Авырлык булмаган җирдә төкерергә ярамый, чөнки әйләнә-тирәдә җиһазлар һәм җилләтү системасы урнашкан. Космонавтлар көнкүрешендәге «ски»ләр тагын да бар әле. Гравитация булмаганга, сидек куыгында басым сизелми, шуңа күрә аның тулымы-юкмы икәнлеген аңлап булмый. Андый-мондый күңелсез хәл килеп чыкмасын өчен, өч сәгать саен туалетка барырга туры килә икән.

Ашау

Космонавтларның бар булган сусызландырылган ризыгы кечкенә пакетларга тутырыла. Ашар алдыннан алар аңа Җирдән махсус алып килгән суны кушалар. Һәр өч сәгать саен көпшә аша яки кечкенә кашык белән ашыйлар. Банкаларны духовкада җылыталар. Безнең хәтердә ничектер космонавтларның бәләкәй тюбиклардан файдалануы истә калган. Хәзер космонавтлар өчен ризыкны тюбикларда әзерләмиләр икән. Чөнки йөртергә дә уңайсыз, җитмәсә, савыты да бик авыр, диде ул. Мәсәлән, чагыштыру өчен: бер тюбикның авырлыгы – 160 грамм, ә пакетныкы – 40 грамм.

– Хәзер тюбикларда соуслар, төрле тәмләткечләр һәм бал гына әзерләнә. Ашларны, салат, ботка, сок, десертларны – барысын да сусызландыралар, – диде Сергей Павлович. – Әйтергә кирәк, космонавтларны бик яхшы ашаталар, аларның рационын менюга кергән 215 төр ризыктан төзергә мөмкин. Стартка өч ай кала, алар бары тик галәмгә менәсе ризыклар белән генә туклана башлыйлар. Орбитада үзләренә күбрәк нинди ризык кирәклеген ачыклыйлар. Исемлек төзиләр. Шуннан соң гына һәр космонавтның шәхсән үзе өчен 16 тәүлеклек рацион төзиләр. Бу рацион беркайчан да кабатланмый. Микрогравитация шартларында кан әйләнеше процессы үзгәрү сәбәпле, тәм сизү рецепторлары да үзгәрә. Мәсәлән, әчкелтем ризык баллы тоелырга, киресенчә булырга да мөмкин. Шуңа күрә орбитада күп вакытта ризык белән алыш-биреш ясыйлар. Биш тапкыр ашау каралган: иртәнге аш, әбәт, кичке аш. Алар арасында ике тапкыр тамак ялгап алалар. Чит ил космонавтлары үз ризыкларын алып киләләр.

Горурлык

Үзәктә нәкъ менә «Мир» станциясенә мөнәсәбәт аеруча җылы кебек тоелды безгә. Сергей Евсеев та аны берничә тапкыр «безнең горурлыгыбыз» дип атады. Тарихы белән танышкач, шулай икәнлегенә без дә инандык.

«Мир» станциясе галәмгә 1986 елның 19 февралендә җибәрелә. Тәгаенләнгән 5 урынына 15 ел эшли һәм 2001 елда Тын океанга батырыла. Шушы чорда анда 28 экспедиция составында 12 илдән 104 космонавт була. «Мир»да фәнни тәҗрибәләр эшләнә, төрле рекордлар куела. 1976 елдан төзелә башлаган бу проектта төрле елларда 280 предприятие катнаша. Ниһаять, 1985 елның 2 гыйнварында СССР Министрлар Советы «Мир» космик орбиталь станциясен төзү турында карар кабул итә.

Станцияне Байконур космодромыннан беренче тапкыр 1986 елның 16 февралендә җибәреп карыйлар. Әмма элемтә белән җитешсезлекләр килеп чыгу сәбәпле, бу эш барып чыкмый. Икенче тапкырында, 1986 елның 19 февралендә, барысы да әйбәт үтә. Сергей Павлович әйтүенчә, аның исеме совет халкының тынычлыкка омтылуына ишарә ясый, ягъни космик техниканы тыныч максатларда гына куллануы турында сөйли.

Станциянең тарихы бик бай. Леонид Кизим һәм Владимир Соловьев составындагы экипаж 1986 елның 15 мартында менә. Космонавтлар бортта ике айга якын эшлиләр. Аннан соң тарихта беренче тапкыр бер орбиталь аппараттан икенчесенә күченәләр. 29 июньдә яңадан «Мир»га кайтып, 16 июльдә Җиргә төшәләр. 1987 елда «Мир»га беренче чит ил кешесе – Сүрия космонавты Мөхәммәт Фарис менә. Ә 1990 елда беренче журналист, Япония космонавты Тоехиро Акияма була. Космонавт Сергей Крикалевның язмышы бик үзенчәлекле: ул 1991 елның маенда илебез СССР дип аталганда менеп китә һәм 1992 елда Россиягә кайтып төшә. Бу очыш өчен ул Россия Герое исеменә лаек була һәм «Волга» машинасын алучы соңгы космонавт буларак тарихка кереп кала. 1994–1995 елларда космонавт Валерий Поляков «Мир»да 437 тәүлек һәм 18 сәгать була. Бу сан хәзерге көнгә кадәр рекорд булып кала.

СССР таркалганнан соң космос өлкәсе дә авыр кризис кичерә. «Мир»да да төрле проблемалар килеп чыга башлый. Иң куркыныч вакыйга 1997 елның 25 июнендә була. Тоташтырган вакытта йөк корабле «Прогресс М-34» «Спектр» модуле белән бәрелешә һәм анда яньчелгән урын барлыкка килә. Ул вакытта станциядә Василий Цибалев, Александр Лазуткин һәм америкалы Майкл Фоуп була. Җирдән зыян күргән модульгә керү урынын герметизацияләргә боерык бирелә. Ләкин люкны ябарга кабельләр комачаулый. Аларны кисеп, җыеп алганнан соң гына станциядән чыккан һаваны туктатырга мөмкинлек туа. Авария нәтиҗәсендә «Мир» электр энергиясенең 40 процентын югалта, шулай итеп, фәнни тәҗрибәләр үткәрергә берничә мөмкинлек тә калмый.

1998 ел башында башка проблемалар да барлыкка килә. Финанслау да туктатыла. 2000 елда анда соңгы тапкыр Сергей Залатин һәм Александр Калери составындагы экипаж була. Үзләре киткәндә, алар станцияне автоном режимга күчереп калдыралар.

«Мир»ның тарихы 2001 елның 23 мартында тәмамлана. Аңа тоташтырылган «Прогресс» корабле станцияне орбитадан чыгара. «Мир»ның калдыклары Яңа Зеландия белән Чили арасында Тын океанга төшә.

– Хәзер инде галимнәр арасында, әгәр кризис комачауламаса, финанслау туктатылмаса, бәлки, «Мир» станциясен саклап та калып булыр иде, дигән фаразлар да бар. «Мир» үз гомерен галәм белән бәйләгән кешеләр өчен бик кадерле. Күз алдына китерү дә кыен: бу өстәл янында 104 космонавт утырып эшләгән бит, – дип, куллары белән йомшак кына сыйпап куйды Сергей Евсеев.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Уйлы күңел уйлана

«Этегез ит ашыймы?»

Күршебез шалтырата. «Гөлсинә апай, сезнең этегез ит ашыймы?» – ди. Чи иттер дип уйлап, «Юк шул, бозау кадәрле булса да, ашауга бик талымчан, чи итне түгел, пешкән майлы итне дә ашамый әле ул», – дим. Баксаң, сүз пешкән тавык ите турында икән. Бераздан бер пакет ит күтәреп килеп тә җитте.

«Үзебез үстергән чеби ите бу. Өйдәгеләр дә ашамый, эт белән песиләр дә туйды инде, ашамыйлар, – ди. – Болар – пешергәннән, кыздырганнан, шашлыктан калган итләр. Нишләтсәң дә, ашаучы юк…» Йодрык кадәрле тавык ботларын, кул яссуы калынлыгындагы түш итләрен күреп, бер мәлгә тынсыз калдым. Ашалмый калган ит, дигәч, мин сөяк-санаклы өлешләр генә көткән идем. Күңелемә: «Ник алайса шулкадәр хезмәт куеп, үстереп азапланасыз соң?» – дигән сорау килсә дә, үпкәләтермен дип куркып, әйтмәдем. Һәр кешенең үз эше бит бу кадәресе. Ә бездә – бер көтү песи. Әй, рәхәтләнеп сыйланды болар. Алардан күреп, эт тә ашады әле. «Безнекеләрне ике көн бәйрәм иттердең, рәхмәтләр яусын, – мин әйтәм. – Ач утырмасалар да, аның кадәр тавык ите күргәннәре юк иде…»

Адәм баласы гына түгел, эт-мәчеләр дә, мал-туар да бик бозылды хәзер. Барысына да тәмледән-тәмле генә кирәк. Әйткәнемчә, бозау кадәр булса да, этебез чи итне элеп тә капмый, бирәсең икән, әллә нинди үпкәләгән кыяфәт чыгарып, оясына ук кереп китә. Ашы-ите дә майлы булмаска, бөтен ризык бармак пешмәслек җылылыкта гына булырга тиеш. Үзенең яратып ашый торган ризыгы булмаса, көннәр буе ач ятса да, якын килми. Песиләр әле аның белән чагыштырганда талымсыз. Дөрес, алар да сөткә, өй ашавына гына риза түгел. «Вискас»ка үлеп китәләр инде! Тычкан тоту уйларында да юк, өйдән чыкканны каравыллап кына торалар…

Сыер маллары да инде элекке кебек билчәнгә, каты курага, зәңгәр тәтәйгә (әле анысын табуың да икеле) яки саламга кушылган, тәмләткеч урынына сибелгән бер уч печәнгә, «үт-үт»ләп кенә сибелгән онга риза түгел шул. Башакка дигән саламың да йомшак, хуш исле булырга; люцерна икән, сабагы катмаган, яфрагы коелмаган; болын печәне икән, дымлы, сазлыклы урында үсмәгән; костер икән, артык озын булмаска h.б. тиеш. Бу таләпләр кипкән печәнгә дә, яңа чабылганына да бердәй кагыла. Кыш көне ашарлар әле, дип өметләнеп тупласаң да, ашамыйлар шул. Дөрес, бөтен маллар да тузганак яфрагын яраталар, тик анысын җәй буе каян җиткерәсең ди?! Абзарда чагында бер синең маллар гына шундый талымчандыр кебек тоела, сүз иярә сүз чыгып, маллар турында сөйләшә башласаң, моң-зарлар уртакка әйләнә: «Ярты ризык тирескә чыга, чәчәләр, таптыйлар, күпме хезмәт әрәмгә китә».

…Ә балалы кешеләрнең – үз проблемасы: ике-өч балалы гаиләдә бөтен бала да ашаган ризык юк, берсенә бер ризык ошамый, берсе аны яратмый, берсе – моны, диләр. Аларга аптырыйсы да юк бугай.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Белдерү

Кадастровым инженером Хабибуллиным Ильдаром Ибрагимовичем (номер квалификационного аттестата кадастрового инженера 16-14-724, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11, 420107, ildarkhabib@mail.ru, тел.: +79272414666, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляемых кадастровую деятельность 31944) проводятся кадастровые работы в отношении земельного участка, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Ново-Савиновский район, пр. Х. Ямашева с кадастровым номером 16:50:110509:87.

Заказчиком кадастровых работ является Сидоренко Лариса Михайловна (контактная информация: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11. Тел.: +79272414666).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11 4 сентября 2023 г. в 10.00 ч.

С проектом межевого плана можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 1 августа 2023 г. по 1 сентября 2023 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 1 августа 2023 г. по 1 сентября 2023 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:110509:123 (Республика Татарстан, г. Казань, Ново-Савиновский район, пр. Х. Ямашева, д. 61).

При проведении согласования местоположения границ при себе иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Елмай!

Ир – баш, хатын – муен

– Без аерылышырга тиеш. Шулай яхшырак булыр.

– Кем өчен яхшырак?

– Син аны белмисең.

* * *

Хатынымның туган көнен онытткан көнемне мин беркайчан да онытмаячакмын.

* * *

– Синнән яхшы ветеринар чыгар иде.

– Ник алай дисең?

– Синең яныңда гел ниндидер хайваннар бөтерелә.

* * *

Пластик хирургиягә тоткан ярты миллион сум акчам әкренләп үзен аклый башлады: бүген урамда бер ир миңа мандарин тоттырды.

* * *

40 яшьтән соң хатын-кыз аңа ничә яшь икәнен үзе хәл итә.

* * *

– Хатын! Бүген көзгедән шундый куркыныч нәрсәләр күрсәттеләр!

Юмореска

ШАЯННАР ИЛЕ...

Без шаяннар илендә яшибез. Кеше бер-берсен шаяртырга, кызык итәргә ярата. Әле күптән түгел генә Казанның бер супер-пупер кибетендә шундый хәл булган. Һәртөрле маскарад киемнәре киенгән яшьләр кибет янында бер кешене эләктереп алалар да болай диләр:

– Безнең кибеттә бүген акция уза. Ә сез – мең дә беренче сатып алучы. Шуңа күрә менә мондый чарада катнашу хокукы бирелә. Шушы арба белән кибеткә керәсез дә нәрсә кирәк, шуны алып чыгасыз. Әгәр өч минут эчендә өлгерәсез икән, барысы да бушлай. Өлгермәсәгез – ярты бәясенә.

Теге кеше сөенеп кибеткә кереп китә, ә бу шаян төркем шундук эреп юкка чыга. Ну, акциядә катнашучыны үзегез дә күз алдына китерә аласыз инде. Ул йөгерә-йөгерә арбасын тутыра һәм кибет хезмәткәрләренең аптыраулы карашына, кисәтүенә дә игътибар итмичә, касса яныннан узып, урамга атылып чыга. Ә анда беркем дә юк...

Без дә сезгә шундыйрак бер шаяру тәкъдим итәбез. Ә аңа кадәр – кечкенә мәзәк. Бәлки, күпләрегез аны беләдер дә. Шулай да искә төшереп узыйк әле...

– Мин инде беренче сыйныфта гына укырлык дәрәҗәдә түгел, апа, – ди малай укытучыга. – Минем апам өченчедә укый, ә мин аннан күпкә акыллырак, шуңа мине дә өченче сыйныфка күчерсәгез иде.

– Яхшы, – ди укытучы, – әйдә директор янына керәбез. Әгәр ул риза була икән, өченчегә күчәрсең.

Укытучы башта директор янына кереп, хәлне аңлатып бирә.

– Яхшы, – ди директор, – керсен. Мин берничә сорау бирермен, дөрес җавап кайтарса, күчерербез.

Шуннан малайны чакырып алалар. Үзләренчә кечкенә имтихан оештыралар.

– Өчне өчкә тапкырлагач ничә була?

– Тугыз.

Ә алтыны алтыга тапкырласаң?

– Утыз алты.

Шул рәвешле бер сәгать буена директор сораулар яудыра, ә малай күз дә йоммыйча җавап бирә һәм бер тапкыр да хаталанмый. Ниһаять, директор аның теләген үтәргә риза була. Тик укытучы өчен бу – көтелмәгән хәл. Мондый белемле баланы үз сыйныфыннан ерак җибәрәсе килми. Шуңа күрә соңгы чарага ябыша.

– Миңа да берничә сорау бирергә мөмкинме? – ди ул, күзләрендәге хәйләкәрлекне яшерергә тырышып. Әлбәттә, директор да, малай да каршы килми. Һәм укытучы башлый:

– Сыерныкы дүртәү, ә минеке икәү генә. Ул нәрсә була?

– Аяклар, апа.

– Синең чалбарыңда бар, ә минекендә юк?

Директор дулкынланып күзлеген сөртергә тотына. Ә малай тыныч кына җавап бирә:

– Кесәләр.

– Җитте, җитте! – дип бүлдерә директор чираттагы соравын бирергә җыенган укытучыны.

– Бу малайны алтынчы сыйныфка күчерәбез. Ул мин ялгышкан урында да дөрес җавап бирде.

Бу мәзәкне искә төшерү бер дә юктан гына түгел. Игътибарлырак булыгыз. Әзер җавапларга карамыйча гына җавап бирегез. Киттек.

Галәмдәге ерак йолдызларны күрергә ярдәм итүче җайланма ничек атала?

Җавабыгыз әзерме? Дөрес, әлбәттә. Ул «телескоп» дип атала.

Икенче сорау. Бик кечкенә кисәкчәләрне күрергә ярдәм итүче нәрсә?

Тагын сез хаклы инде. Әлбәттә, микроскоп.

Монысы аз гына катлаулырак. Игътибарлырак булыгыз. Су астында йөргән чакта су өстен күзәтергә ярдәм итүче җайланма ничек дип атала?

Әлбәттә, шулай. Перископ.

Сезнең белемгә һәм тапкырлыкка берничек тә шикләнерлек түгел. Тормышның һәртөрле сорауларына җавап таба-таба чарланып беткәнсез инде. Шулай да дүртенче сорауны бирми булмый. Монысы тагын да катлаулырак. Стена аша карарга булышучы җайланма нәрсә ул?

Яхшырак уйлагыз. Ашыкмагыз. Биреләсез дәмени инде? Ә җавап болай гади генә иде үзе. Тәрәзә дип атала ул.

Тормыш куйган сорауларга җавап биргәндә дә бераз шаянрак булыгыз. Дөреслек бер генә төрле түгел ул, ә шаяруга төрелгән дөреслек һәрвакыт дөрес.

Марат КӘБИРОВ

Һаман истә

Задорнов төртмәләре

Исән булса, танылган юмор остасы Михаил ЗАДОРНОВка 21 июль көнне 75 яшь тулган булыр иде. Әйдәгез әле, аның шаяруларын искә алыйк.

Һәрвакыт яхшы кәефтә буласыгыз килсә, кечкенә генә әйбергә дә шатланырга өйрәнегез. Мәсәлән, хезмәт хакына.

Әгәр дә реформа игълан ителә икән, димәк, казнадан акча урларга җыеналар. Яки инде урлаганнар.

Рус балалары Сан-Хосе шәһәре мәктәбенә өч дуңгыз җибәргән. Сыртларына 1, 2 һәм 4 дип язганнар. Полиция бер атна буе өченче номерлы дуңгызны эзләгән.

Бары тик безнең кеше генә тырмага икенче тапкыр баскач, чын күңеленнән шатлана: тырманы урламаганнар бит!

Әгәр дә хатын-кыз «юк» дип әйтә икән, бу «әйе» дигәнне аңлата, әмма соңрак.

Бездә эвакуация планын аңлаганчы, шул план белән бергә янып бетәчәксең.

Әгәр сезнең күзләрегез җитди, ә иреннәрегез юләр сыманрак елмая икән – димәк, сезне паспортка фотога төшерәләр.

Бездә юллар төзегәнче вездеходлар төзү отышлырак дип таптылар, ахрысы.

Кеше арасындагы дуслыкка бөтенләй өмет калмады дигән сүз бит инде, бензопилага «Дружба» исеме биргәч.

Россия тарихы ул – тырмалар өстендә дискотека.

Бары тик безнең илдә генә каршы як полосадан барганда арттан килеп бәрелүләре бар.

Ипотека ул төрмә түгел: амнистия көтмәгез.

Оптимист ул – поездга соңга калып, үзен, киләсе поездга вакытлырак килдем, дип тынычландыручы кеше.

Еш кына алга бару ул – артка тибү нәтиҗәсе.

Бүгенге мәктәп программасына карыйм да әниемә мине иртәрәк тудырганы өчен рәхмәт әйтәм.

Йөзгә җиткәнче йөз

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ «ФӘЙЗУЛЛИН ЙӨЗҮЛӘРЕ»НДӘ

«Фәйзуллин йөзүләре» дигән бәйрәм турында ишеткәнегез бардыр. Ишетми ни, күпьеллык тарихы бар бит аның. Быел менә 45 нче тапкыр үткәрелде. Татарстанның халык язучысы Равил Фәйзуллин җәйнең матур бер көнендә дус-ишләрен, язучыларны, журналистларны, иҗат әһелләрен су коенырга алып чыгып китә. Иң осталар берничә чакрымга сузылган озын дистанциягә йөзә. Равил абый үзе бу очрашуны, әдәбият һәм спорт бәйрәме, ди. Мин исә әле юмор бәйрәме дип тә өстәр идем. Мондый шәхесләр җыелган җирдә уен-көлкесез була димени!

Алмаз Хәмзиннның йөзү стиле

Мамадышта йөзәбез. 2021 ел. Ярышта катнашучылар Нократны кичкән арада бәйрәмне алып баручы Алмаз Хәмзинга «бәйләнде». Ә аның исә һәр сорауга тапкыр җавабы әзер.

– Алмаз абый, бу йөзү стиле ничек дип атала? Кроль? Брасс?

– Колач җәеп йөзү дип атала.

– Тегендә кемнәр йөзә икән, башлары буенча танымыйсызмы?

– Хәзер кешене баш буенча танып булмый, башсызлык буенча гына танып була.

– Алмаз абый, Равил Фәйзуллин иҗатын ничек бәялисез?

– Элегрәк аның иҗаты агымга каршы иде. Аннары агым көчәйде.

Римзил Вәлиев төрттергән

Римзил Вәлиев – «Фәйзуллин йөзүләре»нең аксакалы. Казансуның Горький паркыннан старт алган иң беренче ярышларның катнашучысы. Язучылар җыелган җирдә гел төртмә сүз була. Алар шуның белән яши, хәтта шуның белән туена кебек. Равил Фәйзуллинның оста йөзүенә, егетләрчә формада булуына ел да соклану белдерәләр. Әмма иң бормалы комплиментны заманында Римзил Вәлиев әйткән: «Бу Равил Фәйзуллин үзенең шигырьләреннән дә озаграк яшәргә җыена, ахрысы», – дигән ул. Римзил абыйның әлеге сүзләрен һәр ел көлеп искә алалар.

~~Көтү~~ язучылар чираты

Берзаман каләм әһелләре арасында дусларча бәхәс чыкты. Татарстан Язучылар берлеген кем җитәкләгән дә кем җитәкләмәгән. Үч иткәндәй, экс-рәис Рафис Корбан да шушында, бүгенге рәис Ркаил Зәйдулла да әнә чәй эчеп утыра. «Мин булганда фәләнчә иде, хәзер сез килгәч, төгәнчә», – дип кулларын болгый Рафис ага. Шунда җирле җитәкче Ринат Сабирҗанов шаярып әйтеп куйды: «Ярар, үпкәләшмәгез инде. Язучылар берлеген җитәкләүнең дә үз чираты бардыр, менә бездә авылда да көтү чираты булган кебек».

Ярты Казан өчен – ярты казан

Быелгы йөзүләр Биектау районы Олы Кавал авылы янындагы Чулпан күлендә узды. Казаннан килгән язучыларны бик матур кунак иттеләр. Табыннар мул иде. Биектау районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ринат Сабирҗанов кунакларны кыстап болай диде: «Пылауны ашап бетерегез. Анда әле пылау – ярты казан». Өстәлнең икенче башыннан җавап ишетелде: «Борчылма, ашап бетерербез, без үзебез дә монда – ярты Казан!»

КЕМ ЯЛГЫШКАН?

Әй, сайрады бер саескан
Күрше бакчада чыр-чыр.
Әни әйтте: «Күршеләргә
Кунак килер, күр дә тор».

Кунаклар безгә килде шул,
Уйлап йөримен эчтән:
Саескан ялгышты микән,
Әллә кунаклар микән?

Фәнис ЯРУЛЛИН

Әз-мәз мәзәк

Җәмәгать мунчасында гел шундый кеше була: кайнар мичкә бер чүмеч су тондыра да: «Уф, бигрәк эссе», – дип чыгып тая.

* * *

Үземә генә күңелсез. Берәр матур гына компания кирәк миңа. Әйтик, нефть чыгару компаниясе.

* * *

Яратам мин йолдызнамә укырга. Анда минем акчам да бар, бөтен кеше белән мөнәсәбәтләрем дә яхшы, диңгезгә дә чыгып кергәлим.

Мач әйткән!

Владимир ЗВОРЫКИН, телевизор уйлап табучы:

– Телевизорда иң шәп деталь – аны сүндереп кую төймәсе.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 308

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+